**Фәнис Яруллин иҗатына багышланган**
**«Мин тормышка гашыйк» исемле**
**укытучыларның һәм укучыларның I республика фәнни-гамәли**
**конференциясенең нигезләмәсе**

## I. Гомуми нигезләмә

1.1. Нигезләмә Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре", Халыклар дуслыгы ордены кавалеры Фәнис Яруллин иҗатына багышланган «Мин тормышка гашыйк» исемле укытучыларның һәм укучыларның республика фәнни-гамәли конференциясен үткәрүнең максатын, бурычларын, тәртибен билгели.

1.2. Фәнис Яруллин иҗатына багышланган «Мин тормышка гашыйк» исемле укытучыларның һәм укучыларның I республика фәнни-гамәли конференциясе (алга таба — Конференция) «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатында ике елга бер тапкыр үткәрелә.

## II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

Конференция татар әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен һәм Фәнис Яруллинның иҗади мирасын, киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

2.1. Конференциянең бурычлары:
- укытучыларда һәм укучыларда Ф.Яруллин иҗатына һәм татар әдәбиятына мәхәббәт, милли үзаң тәрбияләү;
- хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсе, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;
- әдәбият өлкәсендә сәләтле балаларны барлау,ачыклау һәм үстерү;
- укытучыларда һәм укучыларда фәнни-эзләнү,тикшеренү күнекмәләре формалаштыру;

## III. Конференцияне оештыручылар

Конференцияне оештыручылар:
– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан муниципаль берәмлеге шәһәр мәгариф берәмлеге;
- Казан (Идел буе) федераль университеты;
- Татарстан Республикасы Язучылар берлеге.
– Казан шәһәре Яңа Савин районының «103 нче рус-татар урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет оешмасы;

## IV. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

4.1. Конференциягә җибәрелгән фәнни-гамәли һәм иҗади эшләргә Татарстан Республикасының танылган сәнгать әһелләреннән, фән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган жюри бәя бирә.

4.2. Конференциядә катнашу бушлай. Конференциягә җибәрелгән эшләр авторларга кире кайтарылмый, әмма автор рөхсәте белән республика мәгълүчараларында кулланылырга мөмкин.

4.3. Конференциядә катнашу тәртибе:

Конференциядә Нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр гариза (Кушымта 1 яки Кушымта 2) белән фәнни-гамәли һәм иҗади эшен җибәргән, Татарстан Республикасы урта һәм өстәмә белем бирү оешмаларында белем алучы 5-11 сыйныф укучылары, шулай ук мәктәп укытучылары катнаша ала.

4.4. Укучыларның фәнни-гамәли һәм иҗади эшләре һәр номинациядә түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:

- 1 нче төркем: 5 - 7 сыйныфлар
- 2 нче төркем: 8 - 9 сыйныфлар
- 3 нче төркем: 10 - 11 сыйныфлар.

4.5. Һәр катнашучыдан билгеләнгән үрнәк буенча персональ мәгълүматларны куллануга ризалык турында белешмә тапшыру таләп ителә (Кушымта 4 - Приложение).

Укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли, иҗади эшләрне үзе сәнгатьле итеп укый, сөйли (эзләнү эше, доклад, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал булырга мөмкин).

Конференциядә чыгыш ясау вакыты – 5-7 минут. Укучы бирелгән вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирә белергә тиеш. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

## V. Конференциянең эш юнәлешләре

Конференциядә түбәндә күрсәтелгән темалар буенча фәнни-тикшеренү һәм ижат эшләре каралачак:

1. **Ф. Яруллин ижаты музыкада**
2. **Әдип ижатында юмор һәм сатира**
3. **Язучы турында замандашлары**
4. **Ф.Яруллин ижатында бәхет** ***(туган як, балачак)*** **темасы**
5. **Татар әдәбияты үсешендә Ф. Яруллин ижатының роле**
6. **Ижат бакчасында (укытучылар өчен)** ирекле темага үзләре язган шигырьләрен, хикәяләрен тәкъдим итәләр. Икенче турга үткән укытучылар бер әсәрне яттан өйрәнеп киләләр.

## VI. Конференция эшләрен бәяләүгә таләпләр

Фәнни-гамәли эшләр, фәнни-эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

- билгеләнгән теманы яктырту,ачып бирә алуы;
- эшкә иҗади якын килү, аргументлаштырылган һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы;

- фәнни-иҗади эшнең укучы яшенә туры килүе;
- заманча компьютер технологияләрен куллану;
- югары дәрәҗәдәге осталык, яңалык, кызыклы идеяләр һ.б.;
- башка конференциядә кулланылмавы;
- грамоталы, әдәби телдә язылган булуы, мисал итеп китерелгән фактларның дөреслеге;
- чыгышны күрсәтмә материаллар, презентацияләр белән баету;
- эшләрдә сылтамалар куелу.

Фәнни-эзләнү эшләре татар телендә кабул ителә. Текстның күләме 5-7 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр) булырга мөмкин (күләме 5-7 бит).

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman – 14, интервал – 1,5; уңнан – 1,5 см; сулдан – 2,5 см, астан – 2 см; өстән – 1,5 см; шигырьләрнең интервалы – 1,0) компьютерда басылган булырга тиеш.

Титул битенә гомуми белем бирү оешмасының тулы исеме, шәһәр, район, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, секциянең темасы, эшнең темасы һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

Конференциягә башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

## VII. Конференцияне үткәрү вакыты

7.1. Конференциядә катнашу өчен гаризалар һәм эшләр **2019 елның 9 декабреннан 2020 елның 8 гыйнварына** кадәр кабул ителә.

7.2. Конференция номинацияләрендә катнашучылар фәнни һәм иҗади эшләрен тиешле гариза һәм « Фәнис Яруллин иҗатына багышланган республика конференциясенә» дигән язу белән **«103 нче рус-татар урта гомуми белем мәктәбе"**нең электрон әрҗәсенә <u>shcool103@mail.ru</u> **һәм почта буенча: 420132, ТР, Казан шәһәре, Яңа Савин районы, Адоратский урамы, 41А** адресына эшләрнең **кәгазь вариантын** җибәрә.

7.3. Конференциянең фәнни һәм иҗади эшләр номинацияләре 2 этапта үтә.

7.4. 1 этап – сайлап алу этабында жюри Конференциягә җибәрелгән фәнни һәм иҗади эшләрне карый һәм иң яхшыларын секцияләрдә чыгыш ясау өчен тәкъдим итә.

7.5. **Жюри эше (2020 елның 8 гыйнварыннан – 2020 елның 1 февраленә кадәр):**

- жюри Конференция номинантларын һәм лауреатларын билгели;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Оештыру комитеты, Конференция дипломантларына Конференциядә катнашу өчен, чакыру хаты җибәрә.

7.6. Оештыру комитеты Конференция рекламасын Татарстан Республикасы мәгълүмат чараларына, интернет порталларына бирергә хокуклы.

## VIII. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

7.1. Фәнни һәм иҗади эшләр язу буенча Конференциядә катнашучылар исемлеге 2020 елның **1 февралендә** билгеле була. Конференция секцияләренд

чыгыш ясаучы укучылар, укытучылар исемлеге **«103 нче рус-татар урта гомуми белем мәктәбе»** сайтында урнаштырыла.

Бәйгене уздыру вакыты: **2020 нче елның 8 нче феврале.**

**Вакыты сәгать 9.00 да. Регистрация сәгать 8.00 дан.**

7.2. Конференция аерым номинацияләрдә иң яхшы фәнни һәм иҗади эш авторларын дипломнар белән билгели.

## VIII. Өстәмә мәгълүмат

Элемтә өчен:
89063-22-82-19 Зиатдинова Нәфисә Вәлиәхмәт кызы
89872-26-73-917 Хафизова Әдилә Ваккас кызы
e-mail: **shcool103@mail.ru**

**Кушымта 1**

Фәнис Яруллин иҗатына багышланган
«Мин тормышка гашыйк» исемле
укытучыларның һәм укучыларның I республика конференциясендә катнашу өчен
гариза (укучылар өчен)

| № | Ф.И.О., авторның туган вакыты, тулы яше, сыйныфы | Автор укыган белем бирү оешмасының тулы исеме | Фәнни яки иҗади номинациясе, эшнең исеме, күләме | Авторның почта буенча тулы адресы, электрон адресы, телефоны | Җитәкченең Ф.И.О.; предметы, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Фәнни яки иҗади эшкә бәяләмә (аннотация)

«____» ___________ 2020 ел.

*Искәрмә: Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Утвержден
приказом Министерства
образования и науки
Республики Татарстан
от «____» ___________2019 г.
№ ____________

Состав жюри
I республиканской научно-практической конференции
имени народного писателя Фаниса Яруллина
«Мин тормышка гашыйк» («Я влюблён в жизнь»)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Шамсутдинова Расима Равиловна | Заведующий кафедрой татарского языка и литературы ГАОУ ДПО «Институт развития образования Республики Татарстан», кандидат филологических наук, доцент |
| 2. | Ялалова Чулпан Ильдусовна | Заведующий учебно-методического отдела ГУП Республики Татарстан «Татарское книжное издательство», переводчик |
| 3. | Ильясова Ильгиза Миркасимовна | Методист по национальному образованию и межрегиональному сотрудничеству учебно-методического сектора Информационно-методического отдела УО ИКМО г.Казани по Ново-Савиновскому и Авиастроительному районам |
| 4. | Зиннатуллин Раиф Каримуллович | Методист по национальному образованию Информационно-методического отдела Управления образования ИКМО г.Казани |
| 6. | Айметов Рамис Киямович | Поэт, переводчик, заместитель председателя Союза писателей РТ |
| | Закиров Марат Халилович | Писатель, консультант Союза писателей РТ |
| 7. | Гыйльманов Галимжан Хамитжанович | Редактор отдела книжнего издательства,писатель, литературный критик, заслуженный деятель искусств РТ |
| 8. | Леронов Лемон Леронович | Главный редактор журнала «Безнең мирас», татарский писатель, поэт, Заслуженный деятель искусств Республики Татарстан |
| 9. | Нигъматов Ирек Гарифуллович | Заместитель главного редактора журнала «Гаилә һәм мәктәп», журналист, писатель |
| 10. | Мухаметзянов Ильяс Мулланурович | Заместитель директора по УР МБОУ «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа № 113 с углубленным изучением отдельных предметов им.Героя России М.Р.Ахметшина», доцент |
| 11. | Зиатдинова Нафиса Валиахметовна | Заместитель директора по вопросам НО МБОУ «Средняя общеобразовательная русско-татарская школа №103» Ново-Савиновского района г.Казани |